СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2020 с. Сарманово № 226

Советның «Сарман муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында » 2009 елның 7 октябрендәге 194 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Сарман муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2009 елның 7 октябрендәге 194 номерлы Совет карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 53 статьяның 2 абзацында «касса керемнәре» сүзләрен «керемнәр» сүзенә алмаштырырга, «касса түләүләре» сүзләрен «күчерүләр» сүзенә алмаштырырга, «бюджетның бердәм счетының фараз халәтен билгеләү максатында, вакытлыча касса аермасын һәм вакытлыча буш акчалар күләмен дә кертеп» сүзләрен өстәргә;

2) 54 статьяның 2 абзацында «Федераль казначылык органнары счетларыннан» сүзләрен «керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3) 55 статьяның 3 пунктында «түләүле һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба - күрсәтмә) һәм» , «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга;

4) 23 статьяның 14 абзацында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 55 статьяның 5 пунктында «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга;

6) 59 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацында «касса» сүзен «казначылык» сүзенә алмаштырырга;

2. «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO TARSTAN .RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль

районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы

Советы Рәисе Ф.М.Хөснуллин